**Җәүһәрова Ф.Х.**
**КФУ доценты**
**Сядия Сяжэфу**
**КФУ, 10-11501 төркем студенты**

## КЫТАЙТАТАРЛАРЫНДА ГАИЛӘ-КӨНКҮРЕШ ФОЛЬКЛОРЫ (БАЛА ТАБУГА БӘЙЛЕ ЙОЛАЛАР)

Халыкны халык иткән нәрсә – аның үзенчәлекле традицион мәдәнияте. Әлеге үзенчәлек югала икән, этнос буларак халык та юкка чыга. Шуңа күрә, бүгенге көндә милли гореф-гадәтләребезне саклау, аны ваклап өйрәнү, кайтару бик зарур.

Татар фольклорына караган беренче мәгълүматлар Пётр I реформаларыннан соңгы елларга ук карый. 1725 нче елда Петербургта фәннәр академиясе оештырыла. Россия империясендә яшәүче халыкларның тарихи этнографиясен өйрәнүгә киң юл ачыла, галимнәр махсус экспедидицияләр оештыруга керешә. Шушы чорлардан соң татар фольклористикасына, этнографиясенә нигез салынып, кызыклы гына материаллар туплана башлый.  Ул хезмәтләр арасына без: Г.Ф.Миллерның “Описание живущих в Казанской губернии языческих народов» (1791), К.Насыйриның «Поверья и обряды Казанских татар, образовавшиеся взаимовлияния на жизнь их суннитского магометанства»(1880), Я.Д.Кобловның “Мифология Казанских татар» (1909), «Религиозные обряды и обычаи татар магометан» (1908) кебек хезмәтләрне дә кертеп карый алабыз. Шул рәттә XX гасыр ахырларында, XXI гасыр башларында дөнья күргән Ф.С.Баязитованың “Гомернең өч туе”, М.Х.Бакировның “Татар фольклоры”, Ф.И.Урманчеевның “Татар халык иҗаты” китаплары да әһәмияткә ия хезмәтләр буларак бәяләнә ала. Татарлар бөтен җиргә сибелгән, шул исәптән Кытайда да җиде меңнән артык татар яши, сан ягыннан бик аз булсалар да, алар бүгенге көнгә кадәр үзләренең милли гореф-гадәтләрен югалтмыйча, буыннан-буынга саклап килә. Ләкин, кызганычка каршы, Кытайда яшәүче

татар халкының гореф-гадәтләре турында бер генә хезмәт тә юк. Бу мәкаләбез шушы эшнең башлангычы булыр дип уйлыйбыз.

Гаилә-көнкүреш йола иҗаты халыкның гаиләдә яшәешенә, көндәлек тормышына бәйләнешле төрле гореф-гадәтләрне, йолаларны һәм шуңа бәйле текстларны үз эченә ала. Галимнәр гаилә-көнкүреш йолаларын 3 төргә бүлеп өйрәнә: бала табуга бәйле йолалар, туй йолалары, үлем, күмү – искә алу йолалары. Бала табуга бәйле йолалар тагын 3 этапка бүлеп өйрәнелә: балага исем кушу; бәби туе; баланы сөннәткә утырту.

Кытайда яшәүче татарларда бала табуга бәйле йолалар туй йолалары белән чагыштырганда шактый тыйнак үткәрелә. Бу йола нигезенә бала һәм ананы “явыз көчләрдән” саклауга, баланың киләчәк тормышын бер кадәр программлаштыруга корылган мифологик ышанулар ситемасы салынган. Әлеге йола комплексы гаиләдә яңа кеше барлыкка килү шатлыгын уртаклашу, аны гаиләгә, нәсел-ыруга кабул итүгә юнәлтелгән гадәтләр эзлеклегенә корылган. Элекке заманнарда Кытайда яшәүче татарларда да баланы кендек әбисе кабул иткән. Гадәттә, бала туу көннәре якынайгач, йөкле хатын-кыз туганнарыннан аерылып торган һәм аның өчен махсус өй хәзерләнгән. Ул өй бик чиста булырга тиеш булган. Элегрәк кайбер авылларда шундый гадәт тә булган, олы яшьтәге әбиләр йөкле хатын-кызны мунчага алып кергән, анда тәлинкә куелган булган, бала табасы хатын кулына йомыртка тоттырылган. Бала табарга тиешле хатын тәлинкә аркылы сикереп, йомыртканы суга ташларга тиеш булган. Болай эшләсә, йөкле хатын баланы җиңел генә таба ала дип ышанылган. Бала туу белән кендек әби баланың кендеген кисеп коендырган һәм чиста биләүгә биләгән. Бүген исә әлеге эш бала тудыру йортында, я әнисе белән баланы өйгә алып кайкач, эшләнә. Бала юындыручыга бүләк бирелә. Өйгә бәби кайткан көнне иң кадерле кунаклар – баланың әнисе ягыннан әби-бабасы килә. Беренче көннәрдән үк өйгә иң якыннар гына килә, чөнки ***“40 көн тулганчы баланы чит кешеләр күзенә күрсәтергә ярамый”*** дигән ышану яши Кытай татарларында. Баланы исемсез озак тотмыйлар. Гадәттә, бала туган беренче өч көн эчендә исем кушу

мәҗлесе үткәрелә  (кайберәүләр бала туып җиде сәгать үтүгә үк тә исем куша). Исем кушу мәҗлесенә мулла, якын туганнар һәм күршеләр чакырыла. Баланың әбисе баланы чиста һәм матур кече юрганга салып,  исем кушучы янына алып килә, аягы кыйбла тарафында булырлык итеп, җәйнамаз өстенә куя. Исем кушучы азан догасы укый, баланың башта уң як колагына “исемегез фәлән булсын” дип өч мәртәбә исемен әйтә, аннан сул як колагына да исем өч тапкыр әйтелә, дога кылына. Баланы алгач, өстәл артына утырып Коръән  укыла,  дога  кылына, изге  теләкләр теләнә: ***“Атын  мин  куштым, яшен Алла бирсен”, “Киемең тузсын, үзең үс”, “Бәхетле-тәүфыйклы бала булсын”***. Болардан соң муллага, килгән кунакларга баланың әти-әнисе сәдака (акча, сабын, кулъяулык, тастымал) бирә. Исем кушу аш белән тәмамлана.

Бала туганнан соң кырык көн буена баланы берүзен генә калдырмыйлар: бу “җен алыштырмасын” өчен шулай эшләнә. Әгәр баланы үзен генә калдырырга туры килсә,  мендәре астына кайчы, пычак көзге салалар. Бу гадәт ***“кайчы җен-пәринең юлын кисә, җен үзен көзгедән күргәч, куркып кача”*** дигән ышануларга корылган. Балага күз тимәсен өчен, баланың башлыгына күз-мунчак элеп куялар, тел тимәсен өчен, корбанлык - сарыкның телен,  кечкенә кисәкләргә кисеп, киеменең бер почмагына тегеп куялар.

Бала туганнан соң 40 көн аралыгында баланы бишеккә салалар. Бала туар алдыннан бишек һәм бүтән җиһазлар әзерләнгән була. Бу көнне әнисе баланы юындыра, кечкенә агач кашык белән бала тәненә су коя, койган вакытта әнисе теләкләрен әйтә: “***тиз, сәламәт үс; белемле, батыр бул; әти-әниеңне хөрмәт ит; әдәп-әхлаклы бул һ.б.”*** Баланы беренче тапкыр бишеккә олы яшьтәге әби сала. Болай сайлауның максаты – баланың да гомере бу олы яшьтәге әбинеке кебек озын булсын дип теләү. Олы яшьтәге әби бишекне кыйбла якка куеп, дога укый һәм  баланы шайтаннардан ерак тоту өчен, адрасман (артыш), кипкән алма белән ысрыклый (ыслый).

Бала туып, 40 көннән соң **“кырык суы”**мәҗлесе үткәрелә**. “Кырык суы”**дигәндә, бала туып 40 көн тулган көнне, аны 40 кашык су белән

теләкләр әйтеп юындыру күзаллана. Бу көн мәҗлес көне була. Гадәттә, бала туып 40 көн булганчы баланың әнисе урамга чыкмый, баласын да бер кешегә күрсәтми. 40 көн булгач, туган-тумача, күршеләр һәм аларның балалары яшь әнине котлап өйгә килә. Алар бөтенесе үз котлау сүзләрен әйтә. Шул көнне баланың чәчен тәҗрибәле, ягъни оста чәч төшерүче төшерә. Кайбер урыннарда әтисе төшерергә тиеш. Шунысы катгый тыелган: хатын-кыз бервакытта да чәч төшерергә тиеш түгел. Баланың чәчен ташларга ярамый, аны җыеп яндыралар, яисә саклыйлар. ***“Кырык су”*** коючы ролен олы яшьтәге, тәрбияле, ире белән тигез гомер кичереп, балалар үстергән сәламәт әби башкара. Ул ***“кырык суы”*** коеп кына калмый, мәҗлескә килгән балаларга махсус пешерелгән тукач (икмәк), ягъни тандырда пешерелгән кабартма һәм хәлвә өлешә. Тукач белән хәлвәне 40 көне тулган бала исеменнән кырык суына килгән балаларга өләшү өчен әнисе әзерли.

Баланың ***“кырык суы”*** өчен яңа тәлинкә әзерләнә, аңа су, әзрәк шикәр, әнисенең алтын йөзеге салына. Әби балага һәр кашык су койганда берәр теләк сүзе әйтә. ***Мәсәлән, гомерең озын булсын, акыллы бул, әхлаклы бала бул һ.б.*** Су кою тәмамлангач, балага яңа киемнәр кидерәләр. Кунакка килгән кечкенә балаларга яңа туган бала исеменнән ***"моны дустыгыз фәлән бирде"*** дип, тукач өстенә халвә салып өләшәләр, килгән өлкән кунакларны әйбәт, тәмле ризыклар белән сыйлыйлар.

Ислам дине кагыйдәләре буенча, ир баланың сөннәтен кылмак фарыздыр. Гадәттә бу так айларда үткәрелә. Баланың яше дә так сан булырга тиеш (күбрәк 7 яшендә үткәрелә һәм көз, яз айларында үткәрелә).

Бу мәҗлес бик зур итеп үткәрелә. Шул көнне җырлар җырлап,бөтен туган, күршеләр котлап килә. Шул көннән бер көн элек баланың әти-әнисе балага яңа юрган, кием, мендәр әзерли. Кайбер җирләрдә бала бер көн элек дуслары белән уйный, ат чаптыра. Дуслары балага яңа кием, билбау бүләк итә һәм бала менгән атка төрле төстәге яулыкларны бәйли.

Операция вакытында бала еласа, аның авызына йомырка салалар.Ул аны ашый да бөтенесен оныта. Операция тәмамлангач, бала берничә көн

караваттан төшми, туганнар һәм дуслары аны күрергә килә.

Шулай итеп, без алып барган күзәтүләр нигезендә, Кытайда яшәүче татарларда гаилә-көнкүреш йолалары гомумитөрки нигезле һәм Казан татарлары йолаларына якын дигән фикергә килеп була.

**Кулланылган әдәбият исемлеге:**


1. Баязитова Ф. С. Гомернең өч туе. – Казан: Тат.кит. нәшр., 1985. – 178 б.
2. Коблов Я.Д. Мифология Казанских татар // Циркуляр по Казанскому учебному округу. 1909. Приложения. №9, - С. 389-436.
3. Коблов Я. Д. Религиозные обряды и обычаи татар – магометан (при наречении имени новорожденному, свадебные обряды и похоронные).- Казань: Изд: ОАИЭ при Каз. Ун-те., 1908, - 46 с.
4. Миллер Г.Ф. Описание живущих в Казанской губернии языческих народов…Спб..: Изд.Академия наук, 1791.
5. К.Насыйри. Поверья и обряды Казанских татар, образовавшиеся мимо влияния на жизнь их суннитского магометанства / Зап. Рус. Геог. Об-ва по отд. Этнографии. – Т.VI. - 1880. – С. 240-270.
6. Урманчеев Ф. И. Татар халык иҗаты. - Казан: Тат. кит. нәшр., 2002.- 238 б.
7. Фукс К.Ф. Казанские татары в статистическом и этнографическом отношениях. – Казань: Тип. Ун-та, 1844.-131с.


**Чыганаклар:**

2011 ел кысаларында оештырылган практика барышында Кытай Халык Республикасы Өремче шәһәрендә тупланган материаллар.